**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 14 август | № 590

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 233 нче, 2015 ел, 11 июнь, 441 нче, 2015 ел, 15 июль, 513 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр арасыннан алар файдаланган җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда Татарстан Республикасы территориясенә дуңгызларның африка чумасын кертү һәм таратуны булдырмау буенча чараларны финанслау тәртибе;

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга дуңгызларның африка чумасын кертүне булдырмау өчен дуңгызларның баш санын сату белән бәйле чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибе.»;

«2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган, әлеге карар белән расланган агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтүгә 2015 елда финанслау күләмнәрен бүлүдә:

17 пунктта «1 833 988,0» саннарын «2 240 894,0» саннарына алмаштырырга:

Таблицага түбәндәге эчтәлекле 34 – 37 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «34. | Крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр арасыннан алар файдаланган җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр | 775,0 |
| 35. | Татарстан Республикасы территориясенә дуңгызларның африка чумасын кертү һәм таратуны булдырмау буенча чараларны финанслау | 15 000,0 |
| 36. | Шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга дуңгызларның африка чумасын кертүне булдырмау өчен дуңгызларның баш санын сату белән бәйле чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр | 567,0 |
| 37. | Шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр | 360 000,0»; |

«Барлыгы» юлында «6 215 404,899» саннарын «6 998 652,899» саннарына алмаштырырга;

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнардан тыш)» сүзләреннән соң «, шулай ук эшчәнлекләрен бер календарь елдан кимрәк гамәлгә ашырган авыл хуҗалыгы оешмаларына (алга таба – яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмалары),» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмаларына, шулай ук 2014 ел белән чагыштырганда 2015 елда чәчү мәйданнарын арттырган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр 2015 елга чәчү йомгаклары турында рәсми статистик хисапны формалаштырган мәгълүмат нигезендә чәчү мәйданыннан чыгып бирелә.»;

текстка түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункт өстәргә:

«$13^1$. Субсидияләр 2015 елның 1 октябре торышына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең төбәк азык-төлек фондына булган кредит бурычын түләүгә бирелә.»;

14 пунктта:

өченче абзацка «,яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмалары – 2015 елга чәчү йомгаклары турында мәгълүматны» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацка «, яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмаларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «, яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмаларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «2015 елның 1 гыйнвары торышына» сүзләреннән соң «, яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмалары – субсидия бирү турында гариза теркәлгән көнгә» сүзләрен өстәргә;

17 пунктның дүртенче абзацына «шуннан соң 2015 елга еллык хисап бирү белән» сүзләрен өстәргә;

текстка түбәндәге эчтәлекле 19[1] пункт өстәргә:

«19[1]. Әлеге Тәртипнең 13[1] пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре һәм яңа оешкан авыл хуҗалыгы оешмалары Идарәгә 2015 елның 1 октябре торышына төбәк азык-төлек фондына булган бурычны тикшерү актларын тапшыралар.»;

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнардан тыш)» сүзләреннән соң «, шулай ук эшчәнлекләрен бер календарь елдан кимрәк гамәлгә ашырган авыл хуҗалыгы оешмалары,» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«үрдәкләр сатып алуга чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү.»;

17 пунктның бишенче абзацына «17» саннарын «11» саннарына алмаштырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле 24[2] пункт өстәргә:

«24[2]. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үрдәкләр сатып алуга чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бер үрдәк башына 303,0 сум исәбеннән бирелә.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үрдәкләр сатып алуга чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү шарты булып үрдәкләрнең баш саны булу тора.

Субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны тапшыралар:

алучы банк раслаган түләү йөкләмәсен, шартнамә күчермәләрен, счет-фактураларны, үрдәкләр сату буенча йөкнамәне;

Министрлык раслаган форма буенча тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпне.»;

күрсәтелгән Тәртипкә 1 нче кушымтада:

2 пунктта 2 «9 335,0» саннарын «5 335,0» саннарына алмаштырырга;

4 пунктта «3 000,0» саннарын «5 000,0» саннарына алмаштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «21 | Үрдәкләр сатып алуга чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр | 2 000,0»; |

күрсәтелгән Тәртипкә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

2015 елда нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең чыгымнарын кире кайтаруга финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 1 154,0 |
| 2 | Азнакай | 3 637,0 |
| 3 | Аксубай | 1 999,0 |
| 4 | Актаныш | 1 188,0 |
| 5 | Алексеевск | 1 810,0 |
| 6 | Әлмәт | 2 197,0 |
| 7 | Апас | 873,0 |
| 8 | Арча | 7 676,0 |
| 9 | Әтнә | 706,0 |
| 10 | Баулы | 158,0 |
| 11 | Балтач | 2 011,0 |
| 12 | Бөгелмә | 27,0 |
| 13 | Буа | 256,0 |
| 14 | Югары Ослан | 121,0 |
| 15 | Биектау | 3 310,0 |
| 16 | Чүпрәле | 605,0 |
| 17 | Алабуга | 86,0 |
| 18 | Зәй | 1 842,0 |
| 19 | Зеленодольск | 4 315,0 |
| 20 | Кайбыч | 161,0 |
| 21 | Кама Тамагы | 681,0 |
| 22 | Кукмара | 1 500,0 |
| 23 | Лаеш | 1 118,0 |
| 24 | Лениногорск | 2 283,0 |
| 25 | Мамадыш | 1 497,0 |
| 26 | Менделеевск | 344,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 27 | Минзәлә | 332,0 |
| 28 | Мөслим | 256,0 |
| 29 | Түбән Кама | 956,0 |
| 30 | Яңа Чишмә | 439,0 |
| 31 | Нурлат | 609,0 |
| 32 | Питрәч | 1 328,0 |
| 33 | Балык Бистәсе | 333,0 |
| 34 | Саба | 6 615,0 |
| 35 | Сарман | 922,0 |
| 36 | Тәтеш | 685,0 |
| 37 | Тукай | 175,0 |
| 38 | Теләче | 2 165,0 |
| 39 | Чирмешән | 477,0 |
| 40 | Чистай | 869,0 |
| 41 | Ютазы | 767,0 |
| | Барлыгы | 58 483,0»; |

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

3 пунктка «махсуслашкан мелиоратив оешмаларга һәм бүлекчәләргә» сүзләреннән соң «, икмәк пешерү сәнәгате предприятиеләренә, машина-технология компанияләренә» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр авыл хуҗалыгы техникасы, махсуслашкан һәм технологик җиһазлар, корылмалар, махсус һәм йөк автотранспорты, авыл хуҗалыгы продукциясен бүлү, эшкәртү һәм төрү өчен махсуслашкан җиһазлар, икмәк пешерү өчен технологик җиһазлар, бәрәңге, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр үстерү, эшкәртү, саклау өчен корылмалар һәм җиһазлар, терлекчелек объектларын җиһазлау өчен инновацион җайланмалар, газ-мотор техникасы сатып алуга чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга бирелә, алар Россия Федерациясенең Стандартлаштыру, метрология һәм сертификацияләү комитетының 1993 ел, 30 декабрь, 301 нче карары белән расланган Гомумроссия ОК 005-93 (ОКП) продукция классификаторына туры килүе шартларында Россия Федерациясендә яки Таможня берлегенең бердәм таможня территориясе илләрендә җитештерелсә.»;

5 пунктта:

«б» пунктчасының икенче абзацында «терлек һәм кош-корт чалу өчен махсуслашкан җайланма» сүзләрен «махсуслашкан һәм технологик җиһазлар» сүзләренә алмаштырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле «и» һәм «к» пунктчаларын өстәргә:

«и) икмәк пешерү сәнәгате предприятиеләренә икмәк пешерү технологик җиһазларын сатып алуга – ӨКС исәпкә алмыйча, аларның бәясе, монтажлау һәм транспорт хезмәтләре күрсәтүнең 40 проценты күләмендә;

к) машина-технология компанияләренә финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча сатып алынган техника өчен, ӨКС исәпкә алмыйча – агымдагы лизинг түләүләренең 40 проценты күләмендә.»;

12 пунктның беренче абзацында «а» – «е», «з» пунктчаларында» сүзләрен «а» – «е», «з», «и» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пунктын өстәргә:

«$12^1$. Әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы «к» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гаризаны;

Министрлык раслаган форма буенча тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпне;

тиешле техниканы куллану өчен сатып алу максатларында төзелгән финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе, күрсәтелгән шартнамәгә карата техниканы кабул итү-тапшыру акты, спецификация һәм өстәмә килешүләр (булганда) күчермәләрен;

финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрендә күрсәтелгән графиклар нигезендә яисә шартнамәләргә кушымталарда күрсәтелгән түләүләрнең чагыштырма графигы нигезендә 2015 елга агымдагы лизинг түләүләрен түләү турында банк өземтәләре белән банк раслаган түләү йөкләмәләрен;

техниканың паспорты күчермәсен.»;

13 пунктның өченче абзацында «12 пунктка» сүзләрен «12 һәм $12^1$ пунктларга» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктның икенче абзацында «а» – е» пунктчаларында» сүзләрен «а» – «е», «з» – «к» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтада:

«Өстәмә лимит (төбәк азык-төлек фондын булдыру максатларында тапшырылган ашлык өчен)» юлында «60 700» саннарын «412 606» саннарына алмаштырырга;

44 пунктта «50 000» саннарын «40 000» саннарына алмаштырырга;

47 пунктта «51 488» саннарын «21 488» саннарына алмаштырырга;

48 пунктта «терлек һәм кош-корт чалу өчен махсуслашкан җайланма өчен» сүзләрен «махсуслашкан һәм технологик җиһазлар» сүзләренә алмаштырырга;

52 пунктта «30 000» саннарын «25 000» саннарына алмаштырырга;

53 пунктта «60 000» саннарын «55 000» саннарына алмаштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 55 һәм 56 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «55 | Икмәк пешерү сәнәгате предприятиеләре | 50 000 |
| 56 | Машина-технология компанияләре | 55 000»; |

«Барлыгы» юлында «1 833 988» саннарын «2 240 894» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга «2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр арасыннан алар файдаланган җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда Татарстан Республикасы территориясенә дуңгызларның африка чумасын кертү һәм таратуны булдырмау буенча чараларны финанслау тәртибен, 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга дуңгызларның африка чумасын кертүне булдырмау өчен дуңгызларның баш санын сату белән бәйле чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибен (теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\590.docx